Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты

КАРАРЫ

«14» январь 2019 ел №02

«Алсу» микрорайоны территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү буенча документлар әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьясы нигезендә, «Әлмәт шәһәре»муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча Комиссия бәяләмәсе нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Шәхси эшмәкәргә Асылкаев З.А.га үз акчалары хисабына «Алсу» микрорайоны территориясендә, гомуми мәйданы 150 кв. м. дан артык булмаган “беренче кирәкле товарлар кибетләре” җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалану төрен билгеләү һәм кызыл линияләрне үзгәртү өлешендә, кадастр номеры 16: 45: 050112: 10 булган җир кишәрлегенә карата үзгәрешләр кертү буенча проект документациясен әзерләүгә керешергә тәкъдим итәргә.

2. «Әлмәт муниципаль районы һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе турында әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Мөхәммәтҗанов А.А. йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев